**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Школьная, д.5, с.Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс (84396) 4-22-23 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

№120 18.12.2023 ел

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 июнендәге № 101 карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы, «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2023 елның 27 июнендәге № 101 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4.13 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «4.12. Класс чины бирү көне дип класс чины бирү турында карар кабул ителгән көн санала».

1.2. 4.19 пунктны төшереп калдырырга.

1.3. 4.21 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында карар, әлеге Нигезләмәнең 4.15 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, класс чинын бирү турында барлык кирәкле документлар белән органга яки җирле үзидарәнең класс чинын бирергә вәкаләтле вазыйфаи затына тапшыру турында тәкъдим кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш».

2. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Р.Гатина